ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

2026 елга Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
туристлык-туган якны өйрәнү,
экология - биология, хәрби - патриотик,
социаль - педагогик, социаль - икътисадый,
табигый-фәнни, техник һәм культурологик
юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү
мәгариф оешмаларының һәм балаларга
өстәмә белем бирүнең күп профильле
мәгариф оешмаларының норматив
чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. 2026нчы елга расларга:

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру юлы белән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикле, инвалид булган укучылар өчен өстәмә

гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга 0,9 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә финанслау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А.А.Ахметшин

Әзерләде һәм бастырды
Е.Б. Соловьева

Расланды
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының
"___" _____________
20____________№ _____ карары белән

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, 1 укучыга бер елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 9 441 | 17 142 | 20 490 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 9 941 | 17 642 | 20 990 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 9 341 | 17 042 | 20 390 |
| Табигать фәннәре | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |

Расланды
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының
"___" _____________
20___________№ ____ карары белән

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру юлы белән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикле, инвалид булган укучылар өчен өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Елына норматив чыгымнар, сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | терәк-хәрәкәт аппараты бозылулары, психик үсеше тоткарлануы, аутистик спектры бозылулары һәм үсешендә күп төрле авырлыклар булган бер укучыга | | | ишетү сәләте начар булган бер укучыга: саңгырауларга, начар ишетүчеләргә, соңрак саңгыраулангannнарга | | |
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 19420 | 31968 | 35316 | 13764 | 23619 | 26967 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 19920 | 32468 | 35816 | 14264 | 24119 | 27467 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 19320 | 31868 | 35216 | 13664 | 23519 | 26867 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |